**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 октябрендәге 4553 номерлы карары**

## 2025 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 16 статьясындагы 13 өлешнең 1 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. 2025 елга расларга:

1.1. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативларын (1 номерлы кушымта);

1.2. Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләмен (2 номерлы кушымта);

1.3. Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибен (3 номерлы кушымта);

1.4. Казан шәһәренең 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә кабул ителгән балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләменә карата көчеш чорына төзәтү коэффициентлары кулланыла торган мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре исемлеген (4 номерлы кушымта);

1.5. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә 2020 елның 1 гыйнварына кадәр кабул ителгән бала өчен ата-аналар түләве күләменә карата (азык-төлек продуктлары бәясеннән тыш) күчеш чорына төзәтү коэффициентларын (5 номерлы кушымта).

2. Балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә, шул исәптән Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган, вәкаләтле орган белән тиешле килешүләр төзегән хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә кагыла дип билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

3.1. мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләре тарафыннан муниципаль биремнәрне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен 2024 елның 3 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән расланган финанс чыгымнары нормативларын, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ата-аналар түләве нормативларын һәм күләмен исәпкә алып, шулай ук хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартлары нигезендә учреждениеләрнең туктаусыз эшләвен тәэмин итү максатыннан ел саен кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә чыгымнарның нормативтан тыш күләмен исәпкә алып билгеләргә;

3.2. 2025 ел дәвамында бюджет акчаларының үзәкләштерелгән нормативтан тыш күләмен, тарифлар арту сәбәпле, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә һәм учреждениеләрнең финанс эшчәнлеге күләменә кермәгән башка чыгым йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерергә;

3.3. муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү өчен бюджет хисабыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы килешүләр нигезендә ведомство буйсынуындагы мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә субсидияләр күчерүне гамәлгә ашырырга;

3.4. тәрбияләнүчеләр контингенты һәм биләгән мәйданнар үзгәрү өлешендә 2025 елда мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә муниципаль бирем үзгәргән очракта, чыгымнарны 2025 елга Казан шәһәренең җыелма бюджет исемлеге чикләрендә яңадан бүлү турында нигезле тәкъдимнәрне Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә юллауны тәэмин итәргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 23 октябрендәге 3193 номерлы «2024 елга Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4553 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативлары**

1. Азык-төлек продуктларына чыгымнарны исәпкә алмыйча, Казан шәһәрендәге мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренең гомуми үсеш төрендәге төркемнәрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

<table>
<tr><th rowspan="3">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны</th><th rowspan="3">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны</th><th colspan="3">Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче</th></tr>
<tr><th colspan="2">гомуми үсеш төрендәге төркемнәр<br>(шул исәптән төрле яшьтәге)</th><th rowspan="2">мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең гаилә төркемнәре</th></tr>
<tr><th>2 айдан 3 яшькә кадәр</th><th>3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы</th></tr>
<tr><td rowspan="2">5 эш көне</td><td>3</td><td>16745</td><td>13953</td><td>-</td></tr>
<tr><td>4</td><td>20036</td><td>17244</td><td>-</td></tr>
</table>

| **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны** | **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны** | **Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **гомуми үсеш төрендәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәге)** | | **мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең гаилә төркемнәре** |
| | | **2 айдан 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы** | |
| | 5 | 21097 | 17742 | - |
| | 6 | 22157 | 18803 | - |
| | 7 | 37760 | 34892 | 22306 |
| | 9 | 48489 | 42829 | 29067 |
| | 10,5 | 49613 | 43391 | 31860 |
| | 12 | 52405 | 46184 | 33537 |
| | 24 | 53149 | 46815 | 34446 |
| 6 эш көне | 9 | 47382 | 43953 | 29629 |
| | 10,5 | 48506 | 44515 | 30472 |
| | 12 | 53529 | 47307 | 34380 |
| | 14 | 55215 | 48431 | 35223 |
| | 24 | 72549 | 57354 | 43030 |

2. Азык-төлек продуктларына чыгымнарны исәпкә алмыйча, Казан шәһәрендәге мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренең катнаш төрдәге төркемнәрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

<table>
<tr><th rowspan="4">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны</th><th rowspan="4">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны</th><th colspan="4">Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче</th></tr>
<tr><th colspan="4">катнаш төрдәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәге)</th></tr>
<tr><th rowspan="2">2 айдан 3 яшькә кадәр</th><th colspan="3">3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы</th></tr>
<tr><th>ишетмәүче балалар, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, уртача һәм авыр дәрәҗәдә акылга зәгыйфь булган балалар, катлаулы җитешсезлекләре булган балалар, күрмәүче балалар, аутистик спектры бозылган балалар өчен</th><th>психик үсешендә тоткарлыклар булган балалар өчен</th><th>сөйләмнәре нык бозылган балалар, җиңел дәрәҗәдә акылга зәгыйфь булган балалар, амблиопия һәм (яки) күзе кылый булган балалар, начар ишетүче балалар өчен</th></tr>
<tr><td rowspan="6">5 эш көне</td><td>3</td><td>24848</td><td>24848</td><td>18167</td><td>20258</td></tr>
<tr><td>4</td><td>29656</td><td>29656</td><td>22385</td><td>22549</td></tr>
<tr><td>5</td><td>34777</td><td>34777</td><td>26703</td><td>26790</td></tr>
<tr><td>6</td><td>40586</td><td>40586</td><td>28255</td><td>30144</td></tr>
<tr><td>7</td><td>64878</td><td>64878</td><td>51244</td><td>52536</td></tr>
<tr><td>9</td><td>72894</td><td>72894</td><td>57811</td><td>59362</td></tr>
</table>

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | катнаш төрдәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәге) | | | |
| | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | | |
| | | | ишетмәүче балалар, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, уртача һәм авыр дәрәҗәдә акылга зәгыйфь булган балалар, катлаулы җитешсезлекләре булган балалар, күрмәүче балалар, аутистик спектры бозылган балалар өчен | психик үсешендә тоткарлыклар булган балалар өчен | сөйләмнәре нык бозылган балалар, җиңел дәрәҗәдә акылга зәгыйфь булган балалар, амблиопия һәм (яки) күзе кылый булган балалар, начар ишетүче балалар өчен |
| | 10,5 | 79274 | 79274 | 61656 | 63176 |
| | 12 | 86199 | 86199 | 65797 | 67212 |
| | 24 | 132360 | 96412 | 71349 | 74869 |
| 6 эш көне | 9 | 81697 | 81697 | 62293 | 63753 |
| | 10,5 | 89064 | 89064 | 66536 | 70094 |
| | 12 | 96092 | 96092 | 72807 | 74130 |
| | 14 | 106532 | 106532 | 78027 | 81402 |
| | 24 | 156239 | 156239 | 110841 | 116149 |

3. Азык-төлек продуктларына чыгымнарны исәпкә алмыйча, Казан шәһәрендәге мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренең компенсацияләү төрендәге төркемнәрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| **Тәрбияләнүчеләр категориясе** | **Тәрбияләнүчеләр нең яше** | **Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче** | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **биш көнлек эш атнасы** | | | | | | | | | **алты көнлек эш атнасы** | | | | |
| | | **бер көнгә эш сәгатьләре саны** | | | | | | | | | **бер көнгә эш сәгатьләре саны** | | | | |
| | | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **9** | **10,5** | **12** | **24** | **9** | **10,5** | **12** | **14** | **24** |
| Сөйләмнәре нык бозылган балалар | Өч яшькә кадәр | 42868 | 53856 | 62521 | 68045 | 100845 | 129362 | 137212 | 152851 | 239291 | 138778 | 148198 | 165407 | 177965 | 264571 |
| | Өч яшьтән артык | 30648 | 37288 | 41976 | 45606 | 72066 | 88082 | 92792 | 103343 | 109903 | 94359 | 99068 | 111191 | 119040 | 133120 |
| Күрү сәләтен өлешчә югалткан балалар (начар күрүчеләр) | Өч яшькә кадәр | 48450 | 61302 | 71824 | 77350 | 123176 | 151693 | 159541 | 175182 | 261622 | 161111 | 170529 | 187737 | 200295 | 286901 |
| | Өч яшьтән артык | 34002 | 41759 | 47568 | 51198 | 85484 | 101501 | 106211 | 116762 | 123321 | 107778 | 112487 | 124610 | 132459 | 146538 |
| Интеллекты бозылган (акылга зәгыйфь булган) балалар | Өч яшькә кадәр | 42868 | 53856 | 62521 | 68045 | 100845 | 129362 | 137212 | 152851 | 239291 | 138778 | 148198 | 165407 | 177965 | 264571 |
| | Өч яшьтән артык | 30648 | 37288 | 41976 | 45606 | 72066 | 88082 | 92792 | 103343 | 109903 | 94359 | 99068 | 111191 | 119040 | 133120 |
| Ишетү сәләте бозылган | Өч яшькә кадәр | 42868 | 53856 | 62521 | 68045 | 100845 | 129362 | 137212 | 152851 | 239291 | 138778 | 148198 | 165407 | 177965 | 264571 |

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләр нең яше | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | бер көнгә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | бер көнгә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| (ишетмәүче) балалар | Өч яшьтән артык | 43321 | 54312 | 62975 | 68501 | 101298 | 129816 | 137666 | 153305 | 164572 | 139234 | 148654 | 165862 | 178420 | 202238 |
| Күрү сәләтен югалткан (күрмәүче) балалар | Өч яшькә кадәр | 47540 | 60087 | 70308 | 75834 | 119540 | 148058 | 155906 | 171545 | 257985 | 157473 | 166890 | 184101 | 196659 | 283265 |
| | Өч яшьтән артык | 47994 | 60543 | 70762 | 76290 | 119994 | 148511 | 156359 | 171998 | 183266 | 157928 | 167346 | 184557 | 197114 | 220932 |
| Ишетү сәләтен өлешчә югалткан (начар ишетүче) балалар | Өч яшькә кадәр | 42868 | 53856 | 62521 | 68045 | 100845 | 129362 | 137212 | 152851 | 239291 | 138778 | 148198 | 165407 | 177965 | 264571 |
| | Өч яшьтән артык | 36678 | 43627 | 50202 | 53953 | 83778 | 105260 | 109970 | 122091 | 130220 | 111541 | 119389 | 131510 | 140928 | 158902 |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар | Өч яшькә кадәр | 52242 | 66356 | 78144 | 83670 | 138343 | 166860 | 174708 | 190349 | 276789 | 176276 | 185696 | 202905 | 215462 | 302068 |
| | Өч яшьтән артык | 43705 | 53001 | 61918 | 65668 | 111898 | 133380 | 138090 | 150211 | 158338 | 139660 | 147509 | 159630 | 169047 | 187022 |
| Аутистик спектры бозылган балалар | Өч яшьтән артык | 53755 | 67452 | 77247 | 84507 | 126281 | 158316 | 167734 | 186890 | 200111 | 169303 | 180292 | 202588 | 216714 | 246375 |
| Туберкулез интоксикациясе булган балалар | Өч яшькә кадәр | 30195 | 36832 | 41520 | 45152 | 71610 | 87626 | 92337 | 102888 | 154475 | 93907 | 98615 | 110739 | 118587 | 170340 |
| | Өч яшьтән артык | 24316 | 27023 | 31299 | 33196 | 55713 | 68214 | 71354 | 76440 | 81429 | 71354 | 76062 | 81150 | 85859 | 96043 |

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләр нең яше | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, бер елга/тәрбияләнүче | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | бер көнгә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | бер көнгә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **9** | **10,5** | **12** | **24** | **9** | **10,5** | **12** | **14** | **24** |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| Еш авыручы балалар | Өч яшькә кадәр | 30195 | 36832 | 41520 | 45152 | 71610 | 87626 | 92337 | 102888 | 154475 | 93907 | 98615 | 110739 | 118587 | 170340 |
| | Өч яшьтән артык | 24316 | 27023 | 31299 | 33196 | 55713 | 68214 | 71354 | 76440 | 81429 | 71354 | 76062 | 81150 | 85859 | 96043 |
| Катлаулы дефектлары булган балалар | Өч яшькә кадәр | 53302 | 66996 | 70513 | 84051 | 125827 | 157862 | 167280 | 186437 | 291276 | 168848 | 179836 | 202133 | 216259 | 321266 |
| | Өч яшьтән артык | 53755 | 67452 | 77247 | 84507 | 126281 | 158316 | 167734 | 186890 | 200111 | 169303 | 180292 | 202588 | 216714 | 246375 |
| Сөйләмендә фонетик-фонематик житешсезлекләр булган балалар | Өч яшьтән артык | 27404 | 34131 | 37344 | 40891 | 68250 | 80751 | 85461 | 92495 | 97484 | 85462 | 90170 | 98775 | 105055 | 119134 |
| Үсешендә башка тайпылышлар булган балалар | Өч яшькә кадәр | 30195 | 36832 | 41520 | 45152 | 71610 | 87626 | 92337 | 102888 | 154475 | 93907 | 98615 | 110739 | 118587 | 170340 |
| | Өч яшьтән артык | 24316 | 27023 | 31299 | 33196 | 55713 | 68214 | 71354 | 76440 | 81429 | 71354 | 76062 | 81150 | 85859 | 96043 |

4. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы

| **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны** | **Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы, көнгә/тәрбияләнүче** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **гомуми үсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге)** | | **шифаханә төркемнәре, шул исәптән еш авыручы балалар төркемнәре** | | | |
| | **2 айдан 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәр** | **2 айдан 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы** | **«целиакия» авыруы булган балалар өчен 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчы** | **«фенилкетонурия» авыруы булган балалар өчен 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчы** |
| 3-4 | 31,46 | 39,60 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5-6 | 75,47 | 95,08 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 7-12 | 125,81 | 158,45 | 163,23 | 217,65 | 283,11 | 373,94 |
| 24 | 157,25 | 195,61 | 204,04 | 268,69 | 0 | 0 |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4553 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме**

1. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гомуми үсеш төрендәге һәм катнаш төрдәге төркемнәрдә гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Балалар саны | Бер айга бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | |
| | | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы |
| 5 эш көне | 3 | Өчтән ким | 1 013 | 1 020 | 601 | 757 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 507 | 510 | 301 | 379 |
| | 4 | Өчтән ким | 1 034 | 1 067 | 601 | 757 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 517 | 534 | 301 | 379 |
| | 5 | Өчтән ким | 2 047 | 2 280 | 1 444 | 1 819 |

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Балалар саны | Бер айга бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | |
| | | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 024 | 1 140 | 722 | 910 |
| | 6 | Өчтән ким | 2 072 | 2 350 | 1 444 | 1 819 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 036 | 1 175 | 722 | 910 |
| | 7 | Өчтән ким | 3 419 | 3 894 | 2 407 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 710 | 1 947 | 1 204 | 1 516 |
| | 9 | Өчтән ким | 3 664 | 4 033 | 2 407 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 832 | 2 017 | 1 204 | 1 516 |
| | 10,5 | Өчтән ким | 3 688 | 4 042 | 2 407 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 844 | 2 021 | 1 204 | 1 516 |
| | 12 | Өчтән ким | 3 902 | 4 203 | 2 407 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 951 | 2 102 | 1 204 | 1 516 |
| | 24 | Өчтән ким | 4 949 | 5 032 | 3 008 | 3 742 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 475 | 2 516 | 1 504 | 1 871 |
| 6 эш көне | 9 | Өчтән ким | 4 395 | 4 812 | 2 889 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 198 | 2 406 | 1 445 | 1 819 |
| | 10,5 | Өчтән ким | 4 424 | 4 846 | 2 889 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 212 | 2 423 | 1 445 | 1 819 |
| | 12 | Өчтән ким | 4 681 | 5 041 | 2 889 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 341 | 2 521 | 1 445 | 1 819 |

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Балалар саны | Бер айга бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | |
| | | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы |
| | 14 | Өчтән ким | 5 595 | 5 695 | 3 611 | 4 492 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 798 | 2 848 | 1 806 | 2 246 |
| | 24 | Өчтән ким | 5 949 | 6 045 | 3 611 | 4 492 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 975 | 3 023 | 1 806 | 2 246 |

2. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның бер һәм берничә категориясенең физик һәм (яки) психик үсешендәге җитешсезлекләрен квалификацияле коррекцияләү эшчәнлегенә өстенлек бирүче компенсацияләү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Балалар саны | Бер айга бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, сумнарда | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | | | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | | | | |
| | | | махсус дәвалау-савыктыру чараларына мохтаҗ балалар, шул исәптән еш авыручы балалар | | үсешендә башка тайпылышлар булган балалар | | сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар | махсус дәвалау-савыктыру чараларына мохтаҗ балалар, шул исәптән еш авыручы балалар | | үсешендә башка тайпылышлар булган балалар | | сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар |
| | | | өч яшькә кадәр | өч яшьтән артык | өч яшькә кадәр | өч яшьтән артык | өч яшьтән артык | өч яшькә кадәр | өч яшьтән артык | өч яшькә кадәр | өч яшьтән артык | өч яшьтән артык |
| 5 эш көне | 3 | Өчтән ким | 1 159 | 1 016 | 1 159 | 1 101 | 1 101 | 601 | 673 | 601 | 757 | 757 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 580 | 508 | 580 | 551 | 551 | 301 | 337 | 301 | 379 | 379 |
| | 4 | Өчтән ким | 1 256 | 1 039 | 1 256 | 1 125 | 1 125 | 601 | 673 | 601 | 757 | 757 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 628 | 520 | 628 | 563 | 563 | 301 | 337 | 301 | 379 | 379 |
| | 5 | Өчтән ким | 2 301 | 2 152 | 2 301 | 2 363 | 2 363 | 1 444 | 1 618 | 1 444 | 1 819 | 1 819 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 151 | 1 076 | 1 151 | 1 182 | 1 182 | 722 | 809 | 722 | 910 | 910 |
| | 6 | Өчтән ким | 2 336 | 2 230 | 2 336 | 2 442 | 2 442 | 1 444 | 1 618 | 1 444 | 1 819 | 1 819 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 1 168 | 1 115 | 1 168 | 1 221 | 1 221 | 722 | 809 | 722 | 910 | 910 |
| | 7 | Өчтән ким | 4 585 | 4 694 | 4 048 | 4 285 | 4 285 | 3 122 | 3 710 | 2 407 | 3 032 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 293 | 2 347 | 2 024 | 2 143 | 2 143 | 1 561 | 1 855 | 1 204 | 1 516 | 1 516 |
| | 9 | Өчтән ким | 4 842 | 4 920 | 4 306 | 4 496 | 4 496 | 3 122 | 3 710 | 2 407 | 3 032 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 421 | 2 460 | 2 153 | 2 248 | 2 248 | 1 561 | 1 855 | 1 204 | 1 516 | 1 516 |
| | 10,5 | Өчтән ким | 4 874 | 4 936 | 4 337 | 4 511 | 4 511 | 3 122 | 3 710 | 2 407 | 3 032 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 437 | 2 468 | 2 169 | 2 256 | 2 256 | 1 561 | 1 855 | 1 204 | 1 516 | 1 516 |
| | 12 | Өчтән ким | 5 196 | 5 098 | 4 733 | 4 740 | 4 740 | 3 122 | 3 700 | 2 407 | 3 032 | 3 032 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 598 | 2 549 | 2 367 | 2 370 | 2 370 | 1 561 | 1 850 | 1 204 | 1 516 | 1 516 |

| **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны** | **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны** | **Балалар саны** | **Бер айга бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләве күләме, сумнарда** | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **барлыгы** | | | | | **шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе** | | | | |
| | | | **махсус дәвалау-савыктыру чараларына мохтаҗ балалар, шул исәптән еш авыручы балалар** | | **үсешендә башка тайпылышлар булган балалар** | | **сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар** | **махсус дәвалау-савыктыру чараларына мохтаҗ балалар, шул исәптән еш авыручы балалар** | | **үсешендә башка тайпылышлар булган балалар** | | **сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар** |
| | | | **өч яшькә кадәр** | **өч яшьтән артык** | **өч яшькә кадәр** | **өч яшьтән артык** | **өч яшьтән артык** | **өч яшькә кадәр** | **өч яшьтән артык** | **өч яшькә кадәр** | **өч яшьтән артык** | **өч яшьтән артык** |
| | 24 | Өчтән ким | 6 607 | 6 085 | 5 948 | 5 588 | 5 588 | 3 902 | 4 577 | 3 008 | 3 742 | 3 742 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 3 304 | 3 043 | 2 974 | 2 794 | 2 794 | 1 951 | 2 289 | 1 504 | 1 871 | 1 871 |
| 6 эш көне | 9 | Өчтән ким | 5 788 | 5 822 | 5 166 | 5 345 | 5 345 | 3 748 | 4 451 | 2 889 | 3 638 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 894 | 2 911 | 2 583 | 2 673 | 2 673 | 1 874 | 2 226 | 1 445 | 1 819 | 1 819 |
| | 10,5 | Өчтән ким | 5 823 | 5 885 | 5 206 | 5 411 | 5 411 | 3 748 | 4 451 | 2 889 | 3 638 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 2 912 | 2 943 | 2 603 | 2 706 | 2 706 | 1 874 | 2 226 | 1 445 | 1 819 | 1 819 |
| | 12 | Өчтән ким | 6 212 | 6 093 | 5 685 | 5 698 | 5 698 | 3 748 | 4 451 | 2 889 | 3 638 | 3 638 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 3 106 | 3 047 | 2 843 | 2 849 | 2 849 | 1 874 | 2 226 | 1 445 | 1 819 | 1 819 |
| | 14 | Өчтән ким | 7 397 | 6 341 | 6 684 | 5 726 | 5 726 | 4 684 | 5 002 | 3 611 | 4 492 | 4 492 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 3 699 | 3 171 | 3 342 | 2 863 | 2 863 | 2 342 | 2 501 | 1 806 | 2 246 | 2 246 |
| | 24 | Өчтән ким | 7 948 | 7 295 | 7 215 | 6 698 | 6 698 | 4 684 | 5 493 | 3 611 | 4 492 | 4 492 |
| | | Өч һәм аннан күбрәк | 3 974 | 3 648 | 3 608 | 3 349 | 3 349 | 2 342 | 2 747 | 1 806 | 2 246 | 2 246 |

---

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4553 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Казан шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен формалаштыру, билгеләү, үзгәртү һәм алу механизмын билгели.

1.2. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен исәпләү һәм алу тәртибе әлеге учреждениене гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

1.3. Әлеге тәртип Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә, шул исәптән Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган, вәкаләтле орган белән тиешле килешүләр төзегән хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә кагыла. Вәкаләтле орган булып Казан шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән Казан шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, аның белән эш йөртү һәм идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Казан шәһәре Башкарма комитеты структур бүлекчәсе тора.

## II. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләмен исәпләү, билгеләү һәм алу тәртибе

2.1. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме, төркемнең төрен, эш режимын һәм тәрбияләнүченең яшь категориясен исәпкә алып, белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүче бер балага билгеләнә.

2.2. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләме белем бирү учреждениеләрендә балаларны карауга һәм тәрбияләүгә чыгымнарны үз эченә ала.

2.3. Ата-аналардан инвалид балаларны, туберкулез интоксикациясе булган балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве алынмый.

Шулай ук ата-ана түләве түбәндәге очракларда алынмый:

1) Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч тәртиптә күпләп килгән Украина гражданнарының, Донецк Халык Республикасы гражданнарының, Луганск Халык Республикасы гражданнарының, Херсон һәм Запорожье өлкәләре гражданнарының һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган затларның (Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында таныклык күрсәткән көннән Россия Федерациясе гражданлыгы алган көнгә кадәр) балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен;

2) түбәндәге гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларын караган һәм тәрбияләгән өчен:

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

- махсус хәрби операция алып барыла торган зонага командировкага җибәрелгән хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче затлар;

- Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар;

- махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын ирекле үтәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләр;

- махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

- махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнар (үлем турында таныклык күрсәткән көннән).

Шулай ук, язылышу турында таныклык нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче, ирнең (хатынның) беренче (башка) никахтан туган балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве алынмый.

Әгәр ата-ана түләвеннән азат итү өчен нигезләр гамәлдән чыкса, ата-аналар (законлы вәкилләр) әлеге нигезләр гамәлдән чыккан көннән алып 3 эш көне эчендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә бу хакта хәбәр итәргә тиеш.

2.4. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күпбалалы гаиләләр өчен 50 процентка кими.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1992 елның 28 декабрендәге 708 номерлы «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында»гы карары нигезендә, уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны, үги малайларны һәм үги кызларны да кертеп, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмада көндезге уку формасында белем алу шарты белән, 18 яшькә кадәрге һәм (яки) 23 яшькә кадәрге, шулай ук күрсәтелгән категориягә караган, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмада уку белән бәйле рәвештә ата-аналарыннан аерым яшәүче өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләр күпбалалы гаиләләр булып санала. Күпбалалы гаиләнең барлык әгъзалары Россия Федерациясе гражданнары булу шулай ук мөһим шарт.

2.5. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-

аналар түләве 50 процентка киметелгәндә, ата-аналарның үз балалары белән беррәттән әлеге гаиләдә яшәүче үги балалар (башка ата-анада исәпкә алынмаса), шулай ук опекага (попечительлеккә) алынган балалар һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә килешү нигезендә тәрбияләнүче балалар исәпкә алына.

2.6. Ата-ана түләвен киметү түбәндәге документлар җыелмасын тапшырган көннән башлап ел саен гамәлгә ашырыла: ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан бирелгән гариза, бала туу турында таныклыклар күчермәләре, 23 яшькә кадәрге балаларның уку урыныннан белешмәләр, күпбалалы гаилә таныклыгы.

Әгәр ата-ана түләвен киметү өчен нигезләр гамәлдән чыкса, ата-аналар (законлы вәкилләр) әлеге нигезләр гамәлдән чыккан көннән алып өч эш көне эчендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә бу хакта хәбәр итәргә тиеш.

2.7. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве тәрбияләнүче мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә булмаган чорда балаларны туклану белән тәэмин итү чыгымнары күләменә киметелергә тиеш. Балаларны туклану белән тәэмин итү чыгымнары күләме мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен финанс чыгымнары нормативына кертелә торган азык-төлек продуктлары сатып алуга чыгымнар белән тигез күләмдә кабул ителә.

2.8. Балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве түбәндәге очракларда алынмый:

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә агымдагы һәм капиталь ремонт ясау чорында;
- авария хәлендә булу сәбәпле учреждение ябылган очракта;
- бала шифаханә-курорт профильле учреждениеләрдә булу чорында яки мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә булган вакытта алынган һәм күрсәтелгән учреждение каршындагы комиссия тарафыннан расланган авырудан соң озакка сузылган тернәкләнү узу чорында.

Озакка сузылган тернәкләнү дигәндә 30 календарь көннән дә ким булмаган вакыт дәвамында тернәкләнү күз алдында тотыла. Күрсәтелгән вакыт тернәкләнү чорына белешмә биргән медицина оешмасы тарафыннан озайтылырга мөмкин.

2.9. Баланы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы бер мәгариф учреждениесеннән икенчесенә күчергәндә, тәрбияләнүче күчерелгәннән соң, агымдагы айның калган көннәре өчен белем бирү учреждениесендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве кире кайтарылырга тиеш.

2.10. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү учреждениесендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләмендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен каралган чыгымнар, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве хисабына каплана торган азык-төлек продуктларына бәя аерып күрсәтелергә тиеш.

2.11. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карауга һәм тәрбияләүгә финанс чыгымнары нормативы зурлыгы билгеләнгән тәртиптә үзгәргән очракта, мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве гамәлдә булу чоры дәвамында вакытыннан алда яңадан каралырга тиеш.

## III. Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен алу тәртибе

3.1. Мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве, агымдагы айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча, ай саен кертелә.

3.2. Белем бирү учреждениесендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве билгеләнгән вакыттан соң ике атна эчендә кертелмәгән очракта, әлеге сумма гамәлдәге законнар белән каралган тәртиптә түләттерелә.

3.3. Белем бирү учреждениесендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен артык кертелгән ата-аналар түләве тәрбияләнүченең ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә язылган гариза нигезендә кире кайтарыла. Гариза ата-аналар түләвен керткән көннән алып бер ел эчендә тапшырылырга мөмкин.

3.4. Белем бирү учреждениесендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен артык кертелгән ата-аналар түләве тәрбияләнүченең ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә гариза тапшырган көннән алып ике атна эчендә кире кайтарыла.

___________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4553 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә кабул ителгән балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләменә карата күчеш чорына төзәтү коэффициентлары кулланыла торган мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре исемлеге**

| **№ т/б** | **Учреждение атамасы** |
|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «268 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 2 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «299 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 3 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган катнаш төрдәге 366 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, Литвинов урамы, 51 йорт адресы буенча урнашкан) |
| 4 | Казан шәһәре Вахитов районының «Катнаш төрдәге 15 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, Толстой урамы, 16 йорт адресы буенча урнашкан) |
| 5 | Казан шәһәре Вахитов районының «34 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 6 | Казан шәһәре Вахитов районының «14 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мәктәпкәчә бүлек) |
| 7 | Казан шәһәре Вахитов районының «Катнаш төрдәге 289 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, С.Садыйкова урамы, 35 йорт адресы буенча урнашкан) |

| №<br>т/б | **Учреждение атамасы** |
|---|---|
| 8 | Казан шәһәре Идел буе районының «100 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе – Белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мәктәпкәчә бүлек) (Казан шәһәре, Южно-Промышленная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан) |
| 9 | Казан шәһәре Совет районының «230 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 10 | Казан шәһәре Совет районының «233 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 11 | Казан шәһәре Совет районының «100 номерлы билингваль балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, Гвардия урамы, 46/3 йорт адресы буенча урнашкан) |
| 12 | Казан шәһәре Совет районының «Компенсацияләү төрендәге билингваль 155 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, Новаторлар урамы, 4а йорт адресы буенча урнашкан) |
| 13 | Казан шәһәре Совет районының «11 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мәктәпкәчә бүлек) |
| 14 | Казан шәһәре Совет районының «148 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 15 | Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 328 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре, 2 нче Даурия урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан) |
| 16 | Казан шәһәре Совет районының «108 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мәктәпкәчә бүлек) |

______________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4553 номерлы карарына
5 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү буенча уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә 2020 елның 1 гыйнварына кадәр кабул ителгән бала өчен ата-аналар түләве күләменә карата (азык-төлек продуктлары бәясеннән тыш) күчеш чорына төзәтү коэффициентлары**

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең бер көнгә эш сәгатьләре саны | Күчеш чорына төзәтү коэффициентлары |
|---|---|---|
| | | 3 яшьтән 7 яшькә кадәр |
| 5 эш көне | 3 | 1,00 |
| | 4 | 1,00 |
| | 5 | 0,36 |
| | 6 | 0,44 |
| | 7 | 0,43 |
| | 9 | 0,78 |
| | 10,5 | 0,81 |
| | 12 | 0,96 |
| | 24 | 0,64 |
| 6 эш көне | 9 | 0,48 |
| | 10,5 | 0,50 |
| | 12 | 0,67 |
| | 14 | 0,39 |
| | 24 | 0,69 |

________________